# Тема: [h] һәм [х] , [н] һәм [ң] тартыклары


Максат: Укучыларны бу тартыкларны дөрес язарга һәм дөрес әйтергә өйрәтү;

әйтелеш белән язылыш (н, ң) туры килмәү очракларын искәртү, шул хәрефләр кергән сүзләрне сөйләмдә дөрес куллана алу күнекмәләрен үстерү;

халык авыз иҗаты аша балаларда туган телгә мәхәббәт тәрбияләү.

Җиһазлау: Дәреслек, сәяхәт схемасы, сигнал карточкалары, халык авыз иҗаты.

# Безнең маршрут



# «Аваз – хәреф капкасы» аша үтү өчен бирем

**Сигнал карточкалары ярдәмендә сорау урынына дөрес хәреф куеп җавап бирегез**

- мә?абәт
- ?әлак
- мә?әббәт
- ?езмәт

- и?тирам
- ?әйлә
- ?ава
- шә?әр

- ?аман
- ба?адир
- ?әл
- да?и

# Белем сукмагыннан

**Дәреслекнең 50 – 51 нче битен ачыгыз. Кагыйдәне өйрәнеп, [һ], [х], [н], [ң] тартыкларының уртак якларын һәм аермаларын әйтегез.**

## Уртак

**[һ], [х] – саңгырау, өрелмәле тартыклар**

**[н], [ң] – яңгырау, йомык борын тартыклары**

## Аерма

**[х],– кече тел тартыгы**

**[һ] – йоткылык тартыгы**

**[н] – тел-теш тартыгы**

**[ң] –кече тел тартыгы, сүз башында килә алмый**

# Иҗат аланы

**Сүзләрне дөрес итеп укыгыз һәм өчәр пар сүздән җөмләләр төзегез.**

**Аны – аңы, ана – аңа, ансыз – аңсыз, дан – доң-доң, монда – моңда, тун – туң, ун – уң, уен – уең, чан – чаң, яна – яңа.**

# Уен тукталышы

Яңгыр, яу, яу, яу!

Ашлык уңсын ызанда,

Ботка пешсен казанда;

Алтын кашык базарда,

Көмеш кашык болытта.

Нык яварга онытма!

# Күп белүчеләр аланы

## Мәкальләрне дәвам ит

Беләге юан берне егар, ...

Ашаганда колагың селкенсен, ...

Дусыңны дус итә бел, ...

Тел - белемнең ачкычы, ...

Галим белгәнен әйтер, ...

# Тикшерү диктанты

_өйкәл, _ава, китап_анә, мә_әббәт, мә_абәт, _әрәкәт, җи_ан,
^

_алык, _әреф, _әкүмәт, _өнәр, _әҗүм, _әркем, сә_нә, сәя_әт,

рә_мәт, зә_әр, бә_әс, бә_ет, ба_адир, а_әң, _әлак, _әрмәтле,

и_тияр, и_лас, ми_ербан.

# Үз-үзеңне тикшер

һәйкәл, һава, китапханә, мәхәббәт, мәһабәт, хәрәкәт, җиһан,
^

халык, хәреф, хөкүмәт, һөнәр, һөҗүм, һәркем, сәхнә, сәяхәт,

рәхмәт, зәһәр, бәхәс, бәхет, баһадир, аһәң, һәлак, хөрмәтлә,

ихтияр, ихлас, миһербан.